ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «бәйле рәвештә тотылган чыгымнарның компенсацияләрен» сүзләрен «бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрнең компенсацияләрен» сүзләренә алмаштырырга;

2) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында муниципаль
берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына
Татарстан Республикасы территориясендә
гражданнарның аерым категорияләре өчен
җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез
дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү
өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен

бирү турында» Татарстан Республикасы
Законына кушымта

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү методикасы**

1. Әлеге Методика дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары (алга таба – муниципаль берәмлек) бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен каралган.

2. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме ($C_{общ}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{общ} = SUM\ C_i ,$$

монда $C_i$ - i-муниципаль берәмлеге бюджетына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенция күләме.

3. I-муниципаль берәмлеге бюджетына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенция күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_i = (SUM\,(T_{горji} \times П_{регjit} + T_{прi} \times P_{регit}) + SUM\,(N_{горji} \times П_{нерегjit} + N_{прi} \times P_{нерегit})) \times 12\ ай - B_{оргit} ,$$

монда:

j – i-муниципаль берәмлегендә транспорт төре (автобус, троллейбус, трамвай, метрополитен);

t – i-муниципаль берәмлегенең транспорт оешмаларына хезмәт күрсәтә торган автоматлаштырылган система операторы;

$T_{горji}$ – i-муниципаль берәмлегендә шәһәр юлларында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда, транспортның төренә бәйсез рәвештә, бер календарь айда билгеләнгән кадәр йөрү хокукы бирә торган озак вакытка исәпләнгән билетлар белән түләү өчен иң чик максималь тариф, ул түбәндәгеләр тарафыннан билгеләнә:

метрополитенда пассажирлар йөртү өлешендә – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү өлешендә – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тарифларны дәүләт җайга салуы өлкәсендә вәкаләтле органы;

$П_{регjit}$ – киләсе финанс елына һәм план чорына субвенцияләрнең күләме билгеләнә торган елга кадәрге булган елда, i-муниципаль берәмлегенең транспорт

оешмаларына хезмәт күрсәтә торган t-автоматлаштырылган система операторы белешмәләре буенча, і-муниципаль берәмлегендә шәһәр юлларында җайга салына торган тарифлар буенча j-транспорты төрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда бердәй айлык социаль юл йөрү билеты һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты (алга таба тиешенчә – юл йөрү билеты һәм балалар өчен юл йөрү билеты) буенча йөртүләрнең (транзакцияләрнең) айлык уртача саны;

$T_{\text{пр}i}$ – і-муниципаль берәмлегендә шәһәр яны юлларында җайга салына торган тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында бер пассажир/километрга Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тарифларны дәүләт җайга салуы өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнгән иң чик максималь тариф;

$P_{\text{ре}rit}$ – киләсе финанс елына һәм план чорына субвенцияләрнең күләме билгеләнә торган елга кадәрге булган елда, і-муниципаль берәмлегенең транспорт оешмаларына хезмәт күрсәтә торган t-автоматлаштырылган система операторы белешмәләре буенча, і-муниципаль берәмлегендә шәһәр яны юлларында җайга салына торган тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында юл йөрү билеты һәм балалар юл йөрү билеты буенча үтелгән пассажир/километрларның айлык уртача саны;

$N_{\text{гор}ji}$ – і- муниципаль берәмлегендә шәһәр юлларында җайга салынмый торган тарифлар буенча j-транспорты төрендә даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында юл йөрү билеты яисә балалар юл йөрү билеты буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән бер тапкыр йөрү (транзакция) бәясе;

$П_{\text{нере}rjit}$ – киләсе финанс елына һәм план чорына субвенцияләрнең күләме билгеләнә торган елга кадәрге булган елда, і-муниципаль берәмлегенең транспорт оешмаларына хезмәт күрсәтә торган t-автоматлаштырылган система операторы белешмәләре буенча, і-муниципаль берәмлегендә шәһәр юлларында җайга салынмый торган тарифлар буенча j-транспорты төрендә даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында юл йөрү билеты һәм балалар юл йөрү билеты буенча йөрүләрнең (транзакция) айлык уртача саны;

$N_{\text{пр}i}$ – і-муниципаль берәмлегендә шәһәр яны юлларында җайга салынмый торган тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында юл йөрү билеты яисә балалар өчен юл йөрү билеты буенча бер пассажир/километрның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән бәясе;

$P_{\text{нере}rit}$ – киләсе финанс елына һәм план чорына субвенцияләрнең күләме билгеләнә торган елга кадәрге булган елда, і-муниципаль берәмлегенең транспорт оешмаларына хезмәт күрсәтә торган t-автоматлаштырылган система операторы белешмәләре буенча, і-муниципаль берәмлегендә шәһәр яны юлларында җайга салынмый торган тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында юл йөрү билеты һәм балалар өчен юл йөрү билеты буенча үтелгән пассажир/километрларның айлык уртача саны;

$B_{\text{ор}rit}$ – киләсе финанс елына һәм план чорына субвенцияләрнең күләме билгеләнә торган елга кадәрге булган елда, і-муниципаль берәмлегенең транспорт оешмаларына хезмәт күрсәтә торган t-автоматлаштырылган система операторы

белешмәләре буенча, шәһәр юлларында һәм шәһәр яны юлларында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә юл йөрү билетын һәм балалар өчен юл йөрү билетын тулыландырудан і-муниципаль берәмлегендә транспорт оешмаларының еллык кереме күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$В_{орrit} = ((Ц_{в} \times Р_{вt} + Ц_{д} \times Р_{дt}) \times Д_{it}) \times 12 \text{ ай},$$

монда:

$Ц_{в}$ – юл йөрү билетын тулыландыруның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан киләсе финанс елына билгеләнгән бәясе;

$Р_{вt}$ – киләсе финанс елына һәм план чорына субвенцияләрнең күләме билгеләнә торган елга кадәрге булган елда, і-муниципаль берәмлегенең транспорт оешмаларына хезмәт күрсәтә торган t-автоматлаштырылган система операторы белешмәләре буенча, муниципаль берәмлектә тулыландырылган юл йөрү билетларының айлык уртача саны;

$Ц_{д}$ – балалар өчен юл йөрү билетын тулыландыруның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан киләсе финанс елына билгеләнгән бәясе;

$Р_{дt}$ – киләсе финанс елына һәм план чорына субвенцияләрнең күләме билгеләнә торган елга кадәрге булган елда, і-муниципаль берәмлегенең транспорт оешмаларына хезмәт күрсәтә торган t-автоматлаштырылган система операторы белешмәләре буенча, муниципаль берәмлектә тулыландырылган балалар өчен юл йөрү билетларының айлык уртача саны;

$Д_{it}$ – киләсе финанс елына һәм план чорына субвенцияләрнең күләме билгеләнә торган елга кадәрге булган елда, і-муниципаль берәмлегенең транспорт оешмаларына хезмәт күрсәтә торган t-автоматлаштырылган система операторы белешмәләре буенча, шәһәр юлларында һәм шәһәр яны юлларында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында муниципаль берәмлекләрнең барлык транспорт оешмалары тарафыннан пассажирлар йөртүләрнең (транзакцияләрнең) айлык уртача саныннан шәһәр юлларында һәм шәһәр яны юлларында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында пассажирлар йөртүләрнең (транзакцияләрнең) і-муниципаль берәмлеге транспорт оешмаларына туры килә торган айлык уртача өлеше түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Д_{it} = \frac{П_{вдit}}{П_{вдt}},$$

монда:

$П_{вдit}$ – киләсе финанс елына һәм план чорына субвенцияләрнең күләме билгеләнә торган елга кадәрге булган елда, і-муниципаль берәмлегенең транспорт оешмаларына хезмәт күрсәтә торган t-автоматлаштырылган система операторы белешмәләре буенча, шәһәр юлларында һәм шәһәр яны юлларында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында і-муниципаль берәмлегенең транспорт оешмалары тарафыннан юл йөрү билетлары һәм балалар өчен юл йөрү билетлары буенча йөртүләрнең (транзакцияләрнең) айлык уртача саны;

$П_{вдt}$ – киләсе финанс елына һәм план чорына субвенцияләрнең күләме билгеләнә торган елга кадәрге булган елда, t-автоматлаштырылган система операторы белешмәләре буенча, t-автоматлаштырылган система операторы хезмәт күрсәтә торган муниципаль берәмлекләрнең барлык транспорт оешмалары тарафыннан шәһәр юлларында һәм шәһәр яны юлларында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында юл йөрү билетлары һәм балалар өчен юл йөрү билетлары буенча йөртүләрнең (транзакцияләрнең) айлык уртача саны.».

**2 статья**

Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөрткәндә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга субвенцияләр күләме 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетын эшләгәндә түбәндәге үзенчәлекләрне истә тотып исәпләнә дип билгеләргә:

юлда йөргән өчен автоматлаштырылган түләү системасы 2020 елның 1 гыйнварына кадәр кертелгән муниципаль берәмлекләргә карата – i-муниципаль берәмлегендә шәһәр юлларында һәм шәһәр яны юлларында җайга салына торган һәм (яисә) җайга салынмый торган тарифлар буенча j-транспорт төрендә даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында юл йөрү билетлары һәм балалар өчен юл йөрү билетлары буенча йөртүләрнең (транзакцияләрнең) айлык уртача саны; i-муниципаль берәмлегендә җайга салына торган һәм (яисә) җайга салынмый торган тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында юл йөрү билетлары һәм балалар өчен юл йөрү билетлары буенча үтелгән пассажир/километрларның айлык уртача саны турында автоматлаштырылган система операторларының 2019 ел өчен белешмәләре кулланыла;

юлда йөргән өчен автоматлаштырылган түләү системасы 2020 елның 1 гыйнварыннан кертелгән муниципаль берәмлекләргә карата – i-муниципаль берәмлегендә шәһәр юлларында һәм шәһәр яны юлларында җайга салына торган һәм (яисә) җайга салынмый торган тарифлар буенча j-транспорт төрендә даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында юл йөрү билетлары һәм балалар өчен юл йөрү билетлары буенча йөрүләрнең (транзакцияләрнең) айлык уртача саны; i-муниципаль берәмлегендә җайга салына торган һәм (яисә) җайга салынмый торган тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында юл йөрү билетлары һәм балалар өчен юл йөрү билетлары буенча үтелгән пассажир/километрларның айлык уртача саны турында автоматлаштырылган система операторларының 2020 ел өчен белешмәләре кулланыла.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясының гамәли көче 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 16 июль
№ 52-ТРЗ